# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советы Карары

Тымытык авылы № 18-29 01 июнь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты хакында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр кертү белән бәйле

Тымытык авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Тымытык авыл җирлеге Советы карары проектын кабул итәргә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны, 2021 елның 5 июньнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http:// aznakayevo.tatarstan.ru, Тымытык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. 2020 елның 2 июлендә 17.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 75 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин:Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б йорт.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем төзергә

- Гыйләҗева Э.Х. - Тымытык авыл җирлеге башлыгы;

- Ягъфәрова Л.Г. - Тымытык авыл җирлеге депутаты;

- Шайгарданов И.Ш. - Тымытык авыл жирлеге депутаты.

6. Ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркемгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне, гражданнарны кабул итү, исәпкә алуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссия халык алдында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә тиеш.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Э.Х.Гыйләҗева

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Тымытык авыл җирлеге Советы
карарына 1 нче кушымта
«01» июнь 2021 № 18-29

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 гыйнварындагы 38 номерлы карары белән расланган (24.09.2012 №51, 05.08.2013 №68-9, 22.10.2014 №26, 30.09.2015 №9-2, 15.11.2016 №40-22, 17.04.2018 №55-80, 03.09.2018 №63-96, 05.11.2019 №85-139, 17.11.2020 №5-12 карарлар редакциясендә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Тымытык авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертерегә:

1.1. 7 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 17 пунктча өстәргә:
«17) алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

1.2. 47 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:
« - алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http:// aznakayevo.tatarstan.ru., Тымытык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.